**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

29 октябрь 2021 ел № 86 Урыссу ш. т. п.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2018 елның 24 декабрендә кабул ителгән «Ютазы районында сәнәгать паркы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында»гы №47 карарына үзгәрешләр кертү турында

Ютазы муниципаль районы территориясендә инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру, предприятиеләргә һәм оешмаларга ярдәм итү, җитештерүне, сәнәгатьне үстерү, эш урыннарын арттыру максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында» 1999 елның 25 февралендәге 39-ФЗ номерлы Федераль закон, «Конкуренцияне яклау турында» 26.07.2006 ел, № 135-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 елның 7 маендагы 284 номерлы карары, шулай ук «Предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында" Карары, Ютазы муниципаль районы Советының 29.07.2011 ел, № 29 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында инвестицион проектларны гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында” Нигезләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2018 елның 24 декабрендә кабул ителгән «Ютазы районында сәнәгать паркы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында» гы 47 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта « 2021 елга» датасын һәм сүзен «2022 елга» датасы һәм сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы инвестицион проектны гамәлгә ашыру турында шартнамә шартларын бозган вакыттан туктатыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм авыл җирлекләре Советлары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы З. В. Ильясов